**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в параметры осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения**

В целях совершенствования правового регулирования отношений в области охоты и сохранения охотничьих ресурсов **постановляю**:

1. Внести в параметры осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения, утвержденные Указом Президента Республики Татарстан от 12 апреля 2013 года № УП-303 «Об определении параметров осуществления охоты в охотничьих угодьях на территории Республики Татарстан, за исключением особо охраняемых природных территорий федерального значения» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 14 декабря 2013 года № УП-1216, от 12 июня 2014 года № УП-572, от 23 апреля 2015 года № УП-412, от 16 июля 2015 года № УП-654 и от 15 августа 2015 года № УП-724), следующие изменения:

а) в разделе I слово «третьей» заменить словом «четвертой»;

б) раздел III дополнить пунктом 9 следующего содержания:

«9. Любительская и спортивная охота ограничивается следующими сроками:

на зайца-русака – с 15 октября по 10 января;

на норку, белку, енотовидную собаку, куниц, хорей – с 15 октября по 28 (29) февраля;

на водоплавающую, болотно-луговую дичь, перепела, голубей и горлиц – в период летне-осеннего сезона охоты с 17 часов первой субботы сентября по 15 ноября;

на тетерева и вальдшнепа – в период осенне-зимнего сезона охоты с 17 часов первой субботы сентября по 31 декабря.».

2. Настоящий Указ вступает в силу через 10 дней после его официального опубликования.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
10 февраля 2016 года
№ УП-131

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль дәрәҗәдә әһәмияткә ия булган махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, аулау параметрларына үзгәрешләр кертү турында**

Ау һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль әһәмияттәге махсус сакланыла торган табигать территорияләреннән тыш, ауның параметрларын билгеләү турында» 2013 елның 12 апрелендәге ПУ-303 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1216 номерлы, 2014 елның 12 июнендәге ПУ-572 номерлы , 2015 елның 23 апрелендәге ПУ-412 номерлы, 2015 елның 16 июлендәге ПУ-654 номерлы һәм 2015 елның 15 августындагы ПУ-724 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы территориясендәге аучылык биләмәләрендә, федераль дәрәҗәдә әһәмияткә ия булган махсус саклана торган табигать территорияләреннән тыш, аулау параметрларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) I бүлектә «өченче» сүзен «дүртенче» сүзенә алмаштырырга;

б) III бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9. Һәвәскәрләр һәм спорт авы түбәндәге вакыт белән чикләнә:

соры куян аулау – 15 октябрьдән 10 гыйнварга кадәр;

чәшке, тиен, янутсыман эт, сусар, көзән аулау – 15 октябрьдән 28 (29) февральгә кадәр;

су, сазлык-болын кошларын, бүдәнә, күгәрчен һәм урман күгәрченен аулау – җәйге-көзге ау чорында сентябрьнең беренче шимбәсендә кичке сәгать биштән алып 15 ноябрьгә кадәр;

көртлек һәм төлләтәвеч аулау – көзге-кышкы ау чорында сентябрьнең беренче шимбәсендә кичке сәгать биштән алып 31 декабрьгә кадәр».

2. Әлеге Указ рәсми басылган көннән 10 көн үткәч үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы
Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел,10 февраль
№ ПУ-131